Республика Татарстан
Глава
Какре-Елгинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы

ул. Советская, д. 22, село Какре-Елга, Азнакаевский район, 423320

Совет урамы, 22 нче йорт, Кәкре Елга авылы, Азнакай районы, 423320

Тел. (факс) 8(85592) 37-0-47; e-mail: Kelg.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның " 21 " ноябреннән. № 6

2025 елның 01 ноябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәтем торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2025 елның 01 ноябрендәге 2 нче номерлы «2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтем торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Кәтем авлыеда 2025 елның 2 декабренә 13.00 сәгатькә, 2025 елның 01 ноябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәтем торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2025 елның 01 ноябрендәге 2 нче номерлы «2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәтем торак пунктында

гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
Кәтем торак пунктында теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 01.11.2025 № 1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтим Авылы торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 01.11.2025 № 2 карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы,текстны бәян итеп:

“Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 2 төркем инвалидлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне 500 сум күләмендә билгеләп киметергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы:

- урамнарны яктырту ясау (Катем урамында);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (М. Сәхбиев ур. юлын чокырларга таш җәю ремонтлау һәм профильләштерү);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материал, җайланмалар сатып алу, тишелешләрне бетерү, торбаларны алмаштыру);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чаптыру, триммер һәм трактор чапкычы өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту):»

түбәндәге редакциядә:

"Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлегенең Катым торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, 2 төркем инвалидлар өчен бер тапкыр бирелә торган түләүне 250 сум күләмендә билгеләп киметергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Катем һәм М. Сәхбиев урамнарындагы күперләр янындагы юл участокларына вак таш салу);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материал, җайланмалар сатып алу, тишелешләрне бетерү, торбаларны алмаштыру);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чаптыру, триммер һәм трактор чапкычы өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту):»

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Кәкре Елга авылы, Совет ур., 22 йорт;

- Кәтем торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

-Кәтем торак пункты халкына гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарны Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) тиеш.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы
Азнакай муниципаль районы башлыгы И.М.Мөхәмәтҗанов